ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 39 «12» декабрь 2019 ел

Хөкем ителгәннәрнең җәзаларын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларның төрләрен билгеләү турында

РФ Җинаять кодексының 49нчы маддәсе 1нче өлеше нигезендә, РФ Җинаять кодексының 25нче маддәсенең 1нче өлеше нигезендә, хөкем ителүчеләрне Киекле авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәза үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатыннан, Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Киекле авыл җирлеге территориясе чикләрендә: Киекле, Кизләү, Үрнәк авылларында, җинаять-үтәтү инспекцияләре белән килешенеп, мәҗбүри эшләрнең башкару урыннарын билгеләргә.

2. Мәҗбүри эшләрнең төрләрен җинаять-үтәтү инспекцияләре белән килештереп билгеләргә-төзекләндерү һәм яшелләндерү, торак пунктларны төзекләндерү, зиратларны төзекләндерү, юл һәм буалар буйларында куаклар кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, йорт яны территорияләрен, чүп-чардан һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалы белән берлектә Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең ФКУ җинаять-башкарма инспекциясе белән берлектә Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм төзәтү эшләренә хөкем ителгән затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Ганиев

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 декабрендәге 39 номерлы карарына Килештерү кәгазе

«2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм 2020 елга төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»
(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М. Ганиев

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ЖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт майоры Р.Ф.Хамидуллин